МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

04.05.2021 г.Казань № 285

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2021 елның 22 июнендә 7741 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләгән затлар пенсиясенә өстәмә һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә тиешле елларны эшләгән өчен пенсия билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләгән затлар пенсиясенә өстәмә һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә тиешле елларны эшләгән өчен пенсия артыннан мөрәҗәгать итү, аларны билгеләү, түләү һәм илтеп җиткерүне оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2006 елның 09 июнендәге 290 номерлы карарын гамәлгә ашыру максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләгән затлар пенсиясенә өстәмә һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә тиешле елларны эшләгән өчен пенсия билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең кушымтада бирелгән административ регламентын расларга.
2. Әлеге боерык үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры урынбасары Н.В.Бутаевага йөкләргә.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2021 елның 4 маендагы 285 номерлы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләгән затлар пенсиясенә өстәмә һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә тиешле елларны эшләгән өчен пенсия билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләгән затлар пенсиясенә өстәмә һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә тиешле елларны эшләгән өчен пенсия билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең әлеге Административ регламенты (алга таба – Регламент) Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләгән затлар пенсиясенә өстәмә һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә тиешле елларны эшләгән өчен пенсия билгеләү буенча дәүләт хезмәте (алга таба – дәүләт хезмәте) күрсәтү стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларына тиңләштерелгән вазыйфаларның җыелма исемлегендә каралган Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын, Татарстан Республикасының конституция дәүләт вазыйфаларын, Татарстан АССР, Татарстан ССР дәүләт вазыйфаларын һәм аларга тиңләштерелгән, Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын даими нигездә биләгән затларга пенсия билгеләү һәм аңа өстәмә исәпләү өчен әлеге вазыйфаларга тиңләштерелгән Вазыйфаларның җыелма исемлегендә каралган вазыйфаларга тиңләштерелгән вазыйфаларны, Татарстан Республикасы Дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары реестрында каралган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын даими нигездә биләгән затлар мөрәҗәгать итүчеләр булып тора.

Закон нигезендә яки Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышаныч кәгазе нигезендә мөрәҗәгать итүче исеменнән вәкил дә эш итә ала.

1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан күрсәтелә.

1.3.1. Гариза, шул исәптән, электрон документ формасында да, гражданин эштән азат ителгән көнгә дәүләт вазыйфасын яисә дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән Татарстан Республикасы дәүләт органына (алга таба – дәүләт органы) тапшырыла.

Гариза бирелгән көнгә дәүләт органы үзгәртеп корылган яки бетерелгән очракта, гариза Татарстан Республикасы законнары нигезендә үзгәртеп корылган яки бетерелгән дәүләт органы функцияләре тапшырылган дәүләт органына бирелә. Әлеге дәүләт органы булмаса, гариза, кирәкле документларны теркәп, Министрлыкка тапшырыла.

1.3.2. Министрлыкның урнашкан урыны, эш графигы, белешмә телефоннары, Министрлыкның рәсми сайт адресы, шулай ук Министрлыкның электрон почта адресы турында мәгълүмат Министрлыкның рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү реестры» дәүләт мәгълүмат системасында һәм Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында урнаштырылган. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту өчен җаваплы органнар һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр әлеге Регламентның белешмәлек кушымтасында китерелгән.

Министрлыкның эш графигы: көн саен, шимбә, якшәмбе һәм эш көне булмаган бәйрәм көннәреннән тыш, эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләрендә билгеләнә торган эш сәгатьләрендә.

Гаризалар кабул итү графигы: һәр көнне, шимбә һәм якшәмбе һәм эшләми торган бәйрәм көннәреннән тыш, Министрлыкның эш сәгатьләрендә.

Эш графиклары һәм гаризаларны кабул итү графиклары дәүләт органнары тарафыннан гражданнар эштән китү көненә дәүләт вазыйфасын яки дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләгән дәүләт органнарының эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләрендә билгеләнә.

1.3.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында мәгълүмат түбәндәгечә алынырга мөмкин:

1) Министрлык бинасында урнашкан, дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган мәгълүмат стендлары аша. Татарстан Республикасы дәүләт телләрендәге мәгълүмат стендларында урнаштырыла торган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы мәгълүмат әлеге Регламентның 1.3.2, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктчасындагы) белешмәләрне үз эченә ала;

2) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре ярдәмендә – (алга таба – «Интернет» челтәре):

Министрлыкның http://mtsz.tatar.ru рәсми сайтында. Министрлыкның рәсми сайтында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла торган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы мәгълүмат әлеге Регламентның 1.3.2, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктындагы) белешмәләрне үз эченә ала;

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында (http://uslugi.tatarstan.ru/);

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru/);

3) Министрлыкка телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон буенча);

4) Министрлыкка язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә дә) мөрәҗәгать иткәндә (электрон почта адресы: mtsz@tatar.ru).

1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга сала торган норматив хокукый актлар исемлеге (норматив хокукый актларның реквизитларын һәм аларны рәсми бастырып чыгару чыганакларын да күрсәтеп) «Интернет» челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү реестры» дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган.

1.5. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк – дәүләт учреждениесенең яки муниципаль учреждениенең оешу-хокук формасында төзелгән (шул исәптән автономияле учреждение булып тора торган), «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон) таләпләренә җавап бирә торган һәм, шул исәптән электрон формада да, «бер тәрәзә» принцибы буенча дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыруга вәкаләтле оешма;

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыны – дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасы шәһәр (авыл) җирлегендә яки шәһәр округында булдырылган территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы);

техник хата – дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә) кертелгән белешмәләрнең, белешмәләр кертүгә нигез булган документлардагы белешмәләрнең ярашсызлыгына китергән хата (язу, басма хата, грамматик яки арифметик хата).

Әлеге Регламентта дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза дигәндә (алга таба – гариза) дәүләт хезмәте күрсәтелү турында рәсми мөрәҗәгать турында сүз бара (210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясының 1 пункты).

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләп атамасы | Стандартка карата таләпләр эчтәлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәте атамасы | Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләгән затлар пенсиясенә өстәмә һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә тиешле елларны эшләгән өчен пенсия билгеләү | «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» 2006 елның 4 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (алга таба – 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы) 12, 13, 13[1], 15, 16 статьялары; «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (алга таба – 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы) 45, 46 статьялары; Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 елның 9 июнендәге 290 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләгән затларның пенсиясенә өстәмә һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә тиешле елларны эшләгән өчен пенсия билгеләүне сорап мөрәҗәгать итү, аларны билгеләү, түләү һәм җиткерүне оештыру кагыйдәләре (алга таба – Кагыйдәләр) |

| | | |
|---|---|---|
| 2.2. Башкарма хакимият органының атамасы | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | Кагыйдәләрнең 1.4 пункты |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә тасвирлама | Пенсиягә өстәмә (тиешле елларны эшләгән өчен пенсия) билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар | Кагыйдәләрнең 4.1 пункты |
| 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү чоры, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын да исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору чоры, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булган документларны бирү (җибәрү) срогы | Дәүләт хезмәте дәүләт органы яки гражданин тарафыннан тапшырылган гариза һәм документлар Министрлыкка алынган көннән башлап 30 календарь көне эчендә Министрлык тарафыннан күрсәтелә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү туктатыла:<br>- 90 календарь көненнән артмаган чорга, – гражданинның салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына бурычлары булса;<br>- гражданин җитешеп бетмәгән барлык документларны тапшырганчыга кадәр.<br>Гаризага барлык документлар да беркетелмәгән очракта, гражданин Министрлыктан тиешле язма белдерүне алганнан соң 90 календарь көне эчендә җитешмәгән документларны дәүләт органына (Министрлыкка) тапшыра.<br>Әгәр җитешеп бетми торган документлар гражданин тарафыннан Министрлыкның язма белдерүе алынганнан соң 90 календарь көне эчендә | Кагыйдәләрнең 3.1, 3.2, 4.1, 4.6 пунктлары |

| | | |
|---|---|---|
| | тапшырылса, ул вакытта әлеге гаризаны дәүләт органында (Министрлыкта) теркәү көне гариза тапшыру көне булып санала.<br>Әгәр җитешеп бетми торган документлар гражданин тарафыннан Министрлыкның язма белдерүе алынганнан соң 90 календарь көне эчендә тапшырылмаса, ул вакытта җитешеп бетмәгән документларны дәүләт органында (Министрлыкта) теркәү көне гариза тапшыру көне булып санала.<br>Пенсиягә өстәмә (тиешле елларны эшләгән өчен пенсия) билгеләү турында яки аны билгеләүдән баш тарту турында карар чыгарылган көннән башлап 10 календарь көне эчендә Министрлык язмача рәвештә гражданинга пенсиягә өстәмә (тиешле елларны эшләгән өчен пенсия) билгеләү турында яки, сәбәпләрен күрсәтеп, аны билгеләүдән баш тарту турында хәбәр итә. | |
| 2.5. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури булган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә | 1. Әлеге Регламентның 1, 2, 3, 4, 5 нче кушымталарында китерелгән форма буенча гариза;<br>2. Шәхесен, яшен, яшәү урынын, кайсы гражданлыкка каравын таныклаучы документ күчермәсе;<br>3. Яшәү урыны буенча Россия Федерациясе Пенсия фондының территориаль органыннан бирелә торган, картлык буенча вакытыннан алда иминият пенсиясе билгеләү яки инвалидлык буенча иминият пенсиясе билгеләү өчен документлар белән гариза кабул итү турында белдерү күчермәсе, – «Иминият пенсияләре турында» 2013 елның 28 | Кагыйдәләрнең 2.3 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе | декабрендәге 400-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясының 1 өлеше нигезендә картлык буенча иминият пенсиясенә хокук бирә торган яшькә җиткәнче пенсия билгеләнгән очракта;<br>4. Хезмәт кенәгәсенең һәм (яки) Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 66, 66[1] статьялары нигезендә алынган, гражданинның хезмәт эшчәнлеге, хезмәт стажы (2020 елның 1 гыйнварына кадәрге чорлар) турындагы белешмәләрнең күчермәсе;<br>5. Хәрби билет күчермәсе;<br>6. Пенсиягә өстәмәләрне (пенсияләрне) китерү белән шөгыльләнә торган почта элемтәсе оешмасының яисә кредит оешмасының яки башка оешманың реквизитлары, шулай ук шәхси счет номеры.<br>Гражданин гаризага Федераль салым хезмәтенең «Салым түләүче затның (җыем түләүченең, иминият кертемнәрен түләүченең, салым агентының) салымнарны, җыемнарны, иминият кертемнәрен, пеняларны, штрафларны, процентларны түләү йөкләмәләрен үтәве турында белешмә формасын, аны тутыру тәртибен һәм аны электрон формада тапшыру форматын раслау хакында» 2017 елның 20 гыйнварындагы ММВ-7-8/20@ номерлы боерыгы белән расланган форма буенча салым түләүче затның (җыем түләүченең, иминият кертемнәрен түләүченең, салым агентының) салымнарны, җыемнарны, иминият кертемнәрен, пеняларны, штрафларны, процентларны түләү йөкләмәләрен | |

| | | |
|---|---|---|
| | үтәве турында салым органы белешмәсен теркәргә хокуклы.<br>Югарыда күрсәтелгән документлар теркәп гариза шәхсән яки ышанычлы зат аша тапшырылырга мөмкин.<br>Мөрәҗәгать итүчеләрнең законлы вәкилләре (законнарда каралган очракларда) яисә мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдаланучы зат мәнфәгатьләрен яклауга вәкаләтләрен раслый торган документны күрсәтә.<br>Документлар һәм белешмәләр мөрәҗәгать итүче тарафыннан вәкаләтле органнардан – турыдан-туры, шул исәптән, мондый мөмкинлек булган очракта, электрон рәвештә алына.<br>Документларның күчермәләре законнарда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, төп нөсхәләре белән бергә тапшырыла, алар төп нөсхәләрен күрсәтеп тапшырыла һәм Министрлык хезмәткәре тарафыннан таныклана.<br>Гариза, шул исәптән, электрон документ формасында да, гражданин эштән азат ителгән көнгә дәүләт вазыйфасын яисә дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән Татарстан Республикасы дәүләт органына тапшырыла.<br>Гариза бирелгән көнгә дәүләт органы үзгәртеп корылган яки бетерелгән очракта, ул үзгәртеп корылган яки бетерелгән дәүләт органы функция- | |

| | | |
|---|---|---|
| | ләре Татарстан Республикасы законнары нигезендә тапшырылган дәүләт органына бирелә. Әлеге дәүләт органы булмаса, гариза, кирәкле документларны теркәп, Министрлыкка тапшырыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалану өчен гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Министрлыкка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Гариза бланкының электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Нотариаль таныкланган гариза һәм аңа теркәлә торган документлар шулай ук дәүләт органына (Министрлыкка) почта элемтәсе оешмалары аша да җибәрелергә мөмкин.<br>Гариза һәм югарыда күрсәтелгән документлар электрон документлар рәвешендә җибәрелергә мөмкин. Электрон документлар формасында тапшырыла торган гариза һәм документлар Россия Федерациясе законнары нигезендә электрон имза белән таныклана һәм электрон чыганаклардан һәм (яки), «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып, «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы Федераль закон) һәм 210-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә электрон имза белән имзаланып (таныклап) тапшырыла. | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнарына һәм җирле үзидарә органнарына буйсына торган оешмалар карамагындагы һәм Мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук, шул исәптән электрон рәвештә дә, Мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итүче дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча түбәндәгеләр алына:<br>1. хосусый шәхси счет буенча иминият номеры турында белешмәләр – Россия Федерациясе Пенсия фондында;<br>2. хезмәт кенәгәсенең һәм (яки) гражданинның хезмәт эшчәнлеге, хезмәт стажы (2020 елның 1 гыйнварыннан алып) турында белешмәләр күчермәсе – дәүләт органында;<br>3. дәүләт вазыйфасын биләгән чорларны яисә дәүләт хезмәте стажын раслый торган документларның күчермәләре (Татарстан Республикасы дәүләт органының дәүләт граждан хезмәткәрләре реестрларының, башка вазыйфага күчерү турындагы боерыкларның, дәүләт органының атамасын үзгәртү (үзгәртеп кору) турындагы норматив хокукый актларның һ.б. күчермәләре) – дәүләт органында.<br>Гариза гражданин тарафыннан Министрлыкка турыдан-туры тапшырылса, Кагыйдәләрнең 2.2 пунктында каралган очракта, Министрлык тарафыннан ведомствоара хезмәттәшлек каналлары аша өстәмә рәвештә түбәндәгеләр алына:<br>1. дәүләт вазыйфасыннан, дәүләт граждан хезмәте вазыйфасыннан җибәрү турындагы карар күчермәсе – дәүләт (муниципаль) архивында;<br>2. айлык акчалата түләү (акчалата түләү) турында белешмә – дәүләт (муниципаль) архивында; | |

| | | |
|---|---|---|
| | 3. дәүләт хезмәтенең аерым шартлары өчен вазыйфаи окладка өстәмә билгеләү турындагы боерык күчермәсе (2006 елның 1 гыйнварыннан 2018 елның 31 мартына кадәр дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләгән затлар өчен) – дәүләт (муниципаль) архивында;<br>4. дәүләт сере өчен вазыйфаи окладка өстәмә билгеләү турындагы боерык күчермәсе (2005 елның 31 декабренә кадәр дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләгән затлар өчен) – дәүләт (муниципаль) архивында;<br>5. Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментының соңгы тапкыр биләгән вазыйфа буенча Татарстан Республикасы Дәүләт граждан хезмәткәрләре реестрына (алга таба – Реестр) кертү турында расламасы (1997 елның 1 гыйнварыннан 2015 елның 31 декабренә кадәрге чорда дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләгән затлар өчен);<br>6. «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтнең кадрлар составы бердәм мәгълүмат системасы» дәүләт мәгълүмат системасыннан 2016 елның 1 гыйнварыннан башлап дәүләт хезмәткәре биләгән вазыйфа буенча дәүләт хезмәткәрен Реестрга кертү турында белешмәләр;<br>7. салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча Россия Федерациясе бюджет | |

| | | |
|---|---|---|
| | системасы бюджетларына түләнергә тиешле бурычларның булуы (булмавы) турында белешмәләр – Федераль салым хезмәтендә.<br>Мөрәҗәгать итүче югарыда аталган белешмәләрне раслый торган документларны үз инициативасы белән дә тапшырырга хокуклы.<br>Әлеге документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле органнардан алынырга мөмкин, шул исәптән, мондый мөмкинлек булганда, электрон формада да, һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән документларны тапшыру өчен әлеге Регламентта каралган тәртиптә тапшырылырга мөмкин.<br>Югарыда күрсәтелгән белешмәләрдән торучы документларның мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.<br>Министрлык мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итәргә хокуклы түгел:<br>дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;<br>210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, шул исәптән мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт | |

| | | |
|---|---|---|
| | хезмәтен күрсәткән өчен түләү кертелүен раслый торган, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнар, бүтән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалар карамагында булган документларны тапшыруны;<br>дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, дәүләт хезмәтен күрсәткәндә булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны тапшыруны;<br>210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә элегрәк электрон үрнәкләре таныкланган документларны һәм мәгълүматларны кәгазьдә тапшыруны, мондый документларга тамгалар керту яки аларны бетерү дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтүнең кирәкле шарты булып торган очраклардан тыш һәм федераль законнарда билгеләнгән башка очраклардан тыш. | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | 1. Документларда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган бетерелгән, өстәп язылган урыннар, сызылган сүзләр һәм төзәтмәләр булу.<br>2. Әгәр күчермәләре законда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, шәхсән мөрәҗәгать итү очрагында документлар исемлегендәге төп нөсхәләренең күрсәтелмәве.<br>3. Мөрәҗәгать итүченең почта аша яки электрон рәвештә документларның Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланмаган күчермәләрен җибәрүе.<br>4. Әлеге Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелмәгән затның документлар белән мөрәҗәгать итүе. | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре:<br>тапшырылган документлардагы белешмәләрнең дөрес булмавы;<br>16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 15, 16 статьяларында, шулай ук 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 45, 46 статьяларында билгеләнгән шартларның үтәлмәве;<br>гражданинның Россия Федерациясе бюджет системасына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча түләнергә тиешле, пенсиягә өстәмә (тиешле елларны эшләгән өчен пенсия) билгеләү өчен мөрәҗәгать итү көненнән соң 90 көн эчендә җайга салынмаган бурычлары булуы. | Кагыйдәләрнең 4.1, 4.3, 4.6 пунктлары |

| | | |
|---|---|---|
| | Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге очракларда туктатыла:<br>- гражданинның салымнар, җыемнар һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләнергә тиешле башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булганда;<br>- гражданин тарафыннан әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән, җитешеп бетмәгән документларның тапшырылмавы | |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки башка төрле түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә | |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмалардан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |

| | | |
|---|---|---|
| зарури хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре, мондый түләү күләмен хисаплау методикасы турында мәгълүматны да кертеп | | |
| 2.12. Дәүләт хезмәте, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләрне күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь чоры | Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты – 15 минуттан артык түгел.<br>Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән. | Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы Указының (алга таба – Россия Федерациясе Президентының 601 номерлы Указы) 1 пункты |
| 2.13. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатен теркәү вакыты һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада да | Гариза һәм документлар Министрлыкка алынган көнне.<br>Гариза һәм документлар электрон документлар рәвешендә ял көннәрендә яисә эшләми торган бәйрәм көннәрендә килгән очракта, – Министрлыкның ял көненнән яисә эшләми торган бәйрәм көненнән соңгы беренче эш көнендә. | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тутыру урыннарына, һәр дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле булган документларны тутыру үрнәкләре һәм аларның исемлекләре булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибенә, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турындагы федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә әлеге объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр | Дәүләт хезмәте янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән бүлмәләрдә күрсәтелә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла. Көтү залларында (бүлмәләрдә) әлеге Регламентның 1.3.3 пунктының икенче абзацында каралган мәгълүматлар, шулай ук аларны тутыру үрнәкләре белән дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза формалары урнаштырылган мәгълүмат стендлары урнаштырыла.<br>Инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларда (алга таба – объект) законнар һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:<br>а) объектларга каршылыксыз керү һәм чыгу мөмкинлеге;<br>б) дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтә торган объект хезмәткәрләре, ассистив һәм ярдәмче технологияләр, шулай ук алмаштырыла торган кресло-коляска ярдәмендә дә, объект территориясендә мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;<br>в) объектка керә торган урында транспорт чара- | «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы федераль законның 14 статьясы, 15 статьясы |

| | | |
|---|---|---|
| | сына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып һәм, кирәк булганда, хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр ярдәмендә дә;<br>г) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү буенча тотрыклы җитешсезлекләре булган инвалидларга объект территориясе буйлап хәрәкәт итәргә булышу;<br>д) инвалидка объектка кергәндә һәм аннан чыкканда ярдәм итү, инвалидка җәмәгать транспортының уңайлы маршрутлары турында мәгълүмат бирү;<br>е) инвалидларның объекттан һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдән каршылыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен, алар яшәешендәге чикләүләрне исәпкә алып, кирәкле мәгълүмат чараларын тиешенчә урнаштыру, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле тавышлы һәм күрсәтмә мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм текстлы башка төрле һәм Брайльнең рельефлы-нокталы хәрефләре белән һәм контраст фонда башкарылган тамгалардан график мәгълүматны кабатлау;<br>ж) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган форма буенча бирелгән, махсус өйрәтелгән булуын раслый торган документы булган очракта, объектка сукыр- | |

| | | |
|---|---|---|
| | ларны ияртеп йөри торган этне кертү.<br>Инвалидларга законнарда һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, дәүләт хезмәтеннән файдалану алу мөмкинлеге бирү өчен түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:<br>а) инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтү кагыйдәләре турында, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү турында, дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле башка гамәлләрне башкару турында кирәкле ярдәмне күрсәтү;<br>б) ишетү буенча инвалидларга, кирәк булганда, рус ишарә теленнән файдаланып, сурдотәрҗемәчене, тифлосурдотәрҗемәчене объектка кертүне дә исәпкә алып, дәүләт хезмәте күрсәтү;<br>в) инвалидларга башка затлар белән бертигез дәрәҗәдә дәүләт хезмәте күрсәтүгә комачау иткән каршылыкларны бетерүдә кирәкле башка ярдәмне күрсәтү;<br>г) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында (шул исәптән мәгълүмат стендында да) Брайльнең рельефлы-нокталы хәрефләре белән һәм контрастлы фонда башкарылган документлар, белдерүләр, күрсәтмә аңлатмалар, шулай ук аудиоконтур күчермәләре булу.<br>2016 елның 1 июленнән соң реконструкция, модернизация үткән, файдалануга тапшырылган | |

| | | |
|---|---|---|
| | объектларга һәм чараларга карата дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итү өлешендәге таләпләр | |
| 2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән һәркемнең файдалана алырлык булуы һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә кереп эшләү саны һәм аларның вакыты буенча озынлыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән файдаланып та, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә, мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфунк- | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>Министрлык бүлмәләренең җәмәгатьчелек транспортыннан файдалана алу зонасында урнашуы;<br>дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарның инвалидлар өчен үтемле булуы;<br>кирәкле санда белгечләр, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул ителә торган урыннар булуы;<br>мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында тулы мәгълүмат булуы;<br>гаризаны электрон рәвештә тапшыру мөмкинлеге;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләрен мөрәҗәгать итүче тарафыннан электрон рәвештә алу мөмкинлеге;<br>инвалидларга биналарның инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләр күрсәтүгә комачаулый торган башка | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр турында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карарының 2.4 пункты; РФ Президентының 601 Указының 1 пункты; 210-ФЗ номерлы Федераль закон |

| | | |
|---|---|---|
| цияле үзәктә берничә дәүләт һәм (яки) муниципаль хезмәт күрсәтү турында 210-ФЗ номерлы Федераль законның 15[1] статьясында каралган гаризаны (комплекслы мөрәҗәгать) тапшыру юлы белән, башкарма хакимият органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт хезмәте күрсәтү (шул исәптән тулы күләмдә) мөмкинлеге яки мондый мөмкинлекнең булмавы | каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтелүе.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>документларны кабул итү һәм карау чорларының саклануы;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу чорының саклануы;<br>Министрлык белгечләренең әлеге Регламентны бозуына нигезле шикаятьләрнең булмавы;<br>мөрәҗәгать итүченең Министрлык белгечләре белән бәйләнешкә керү саны:<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар турыдан-туры тапшырылганда – икедән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документлар почта аша җибәрелгәндә, – бердән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча).<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең Министрлык белгече белән бер мәртәбә хезмәттәшлек итү вакыты 15 минуттан артмый.<br>Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк аша, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннары аша дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гариза тапшыруны да кертеп, дәүләт хезмәте дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк аша күрсәтелми.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында | |

| | | |
|---|---|---|
| | http://mtsz.tatarstan.ru сайтында, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталында, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында (http://uslugi.tatarstan.ru/) мөрәҗәгать итүче тарафыннан мәгълүмат алу каралмаган.<br>Экстерриториаль принцип буенча һәм комплексы мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми. | |
| 2.16. Экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен дә исәпкә ала торган башка таләпләр | Гариза һәм электрон документ формасындагы документлар дәүләт органына (Министрлыкка), «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан электрон чыганаклардан файдаланып та дәүләт органына (Министрлыкка) тапшырылырга мөмкин. Шул ук вакытта гариза гади электрон имза белән имзаланган булырга тиеш, ә гаризага теркәлә торган документларның күчермәләре 63-ФЗ номерлы Федераль закондагы һәм 210-ФЗ номерлы Федераль законның $21^1$ статьясы һәм $21^2$ статьясы таләпләре нигезендә законнарда билгеләнгән тәртиптә электрон имза белән таныкланган булырга тиеш. | 210-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>63-ФЗ номерлы Федераль закон |

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада да үтәү үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гамәлләр эзлеклелегенә тасвирлама.

3.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү, шул исәптән электрон рәвештә дә, түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү һәм гариза төзү өлешендә дә;

теркәлгән документлар пакеты белән пенсиягә өстәмә (тиешле елларны эшләгән өчен пенсия) билгеләү буенча гариза кабул итү һәм теркәү яки документларны кабул итүдән баш тарту;

мәгълүматлар алу, ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга җибәрү;

пенсиягә өстәмә (тиешле елларны эшләгән өчен пенсия) билгеләү (билгеләүдән баш тарту), дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңартып җибәрү) турында карар әзерләү һәм кабул итү;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен гражданин шәхсән мөрәҗәгать иткәндә мөрәҗәгать итүчегә тапшыру яки дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен почта буенча җибәрү.

техник хатаны төзәтү.

3.2. Мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә.

Мөрәҗәгать итүче шәхсән, телефон аша, почта буенча язмача һәм (яки) электрон почта аша Министрлыкка дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында консультацияләр алу өчен мөрәҗәгать итә.

Министрлык белгече шәхсән, телефон аша, почта һәм (яки) электрон почта аша, мөрәҗәгать итүченең мөрәҗәгать итү ысулына карап, мөрәҗәгать итүчене консультацияли, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның составы, рәвеше һәм эчтәлеге буенча да, гариза бланкы бирә һәм, зарурлык булганда, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: консультацияләү, тапшырылган документларның составы, рәвеше һәм эчтәлеге буенча кисәтүләр, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны рәсмиләштерү өлешендә дә.

3.3. Гариза һәм документларны кабул итү һәм теркәү.

3.3.1. Мөрәҗәгать итүче, әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны (документларның күчермәләрен) теркәп, дәүләт органына

пенсиягә өстәмә (тиешле елларны эшләгән өчен пенсия) билгеләү турында гариза тапшыра.

Дәүләт органы үзгәртеп корылган яки бетерелгән очракта, гариза Татарстан Республикасы законнары нигезендә үзгәртеп корылган яки бетерелгән дәүләт органы функцияләре тапшырылган дәүләт органына бирелә. Әлеге дәүләт органы булмаса, гариза, кирәкле документларны теркәп, Министрлыкка тапшырыла.

Гариза һәм аңа теркәп тапшырыла торган, Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган документларның күчермәләре аларны җибәрү фактын һәм датасын раслау мөмкинлеген бирә торган ысул белән почта аша җибәрелә ала.

Гариза һәм 63-ФЗ номерлы һәм 210-ФЗ номерлы федераль законнардагы таләпләр нигезендә электрон имза белән имзаланган (таныкланган) электрон документлар рәвешендә җибәрелә торган документларның күчермәләре мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт органына (Министрлыкка) электрон чыганаклардан файдаланып һәм (яисә), «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре ярдәмендә тапшырылырга мөмкин.

Почта буенча яисә электрон документ рәвешендә тапшырылган гариза һәм документлар (документларның күчермәләре) әлеге Регламентның 3.3 пунктында каралган тәртиптә карала.

3.3.2. Министрлыкка гариза биргәндә, Министрлык белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

мөрәҗәгать итүченең законлы вәкиле буларак катнашучы затның яисә аның тарафыннан вәкаләт бирелгән затның вәкаләтләрен тикшерә;

кирәкле барлык документлар булуын һәм аларның билгеләнгән таләпләргә (документларны тиешенчә рәсмиләштерү, документларда чистартылган, өстәп язылган, сүзләре сызылган урыннар һәм алдан сөйләшенмәгән башка төзәтү урыннары булу-булмавын) туры килүен тикшерә.

Гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның күчермәләрен (алга таба – документлар) кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.7 пунктында каралган нигезләр булган очракта, Министрлык белгече (мөрәҗәгать итүче шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта) мөрәҗәгать итүчегә документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре булуы турында телдән хәбәр итә һәм, документларны кабул итүдән баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген аңлатып, документларны аңа кайтарып бирә. Мөрәҗәгать итүченең таләбе буенча баш тарту язмача рәсмиләштерелә. Гаризаны һәм документларны почта буенча һәм (яисә), «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре аша алганда, Министрлык белгече гаризаны һәм документларны, документларны кабул итүдән һәм гаризаны теркәүдән баш тарту сәбәпләрен язмача аңлатып, кайтарып бирә.

Документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре булмаган очракта, Министрлык белгече:

гаризаны кабул итә һәм мөрәҗәгатьләрне теркәү журналында (11 нче кушымта) терки;

мөрәҗәгать итүчегә гаризаны һәм документларны кабул итү датасы, алганда беркетелгән номеры (мөрәҗәгать итүче шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта) ту-

рында тамгалап язу тапшыра, ә гариза почта буенча һәм (яки), «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән җибәрелгән очракта, – гаризаны теркәү датасы һәм алынган беркетелгән номеры турында белдерү җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар түбәндәгечә башкарыла:

шәхсән кабул иткәндә яисә гариза һәм документлар почта аша килгәндә – гариза һәм документлар алынган көнне;

гариза, «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре аша килгәндә, – гариза һәм документлар Министрлыкка алынган көнне яисә, гариза һәм документлар Министрлыкның эш сәгате тәмамланган вакытта алынган очракта, – аннан соңгы көндә. Гариза һәм документлар электрон документлар рәвешендә ял көннәрендә яисә эшләми торган бәйрәм көннәрендә килгән очракта, – Министрлыкның ял көненнән яисә эшләми торган бәйрәм көненнән соңгы беренче эш көнендә.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән документлар, гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында теркәү язуы, язу яисә мөрәҗәгать итүчегә кайтарып бирелгән документлар, мөрәҗәгать итүчегә документларны кабул итүдән баш тарту турында телдән (язмача) белдерү.

3.4. Мәгълүматлар алу, ведомствоара мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга җибәрү.

3.4.1. Министрлык белгече ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча электрон рәвештә белешмәләр ала:

хосусый шәхси счет буенча иминият номеры турында белешмәләр – Россия Федерациясе Пенсия фондында;

хезмәт кенәгәсенең һәм (яки) гражданинның хезмәт эшчәнлеге, хезмәт стажы (2020 елның 1 гыйнварыннан алып) турында белешмәләр күчермәсе – дәүләт органында;

дәүләт вазыйфасын биләгән чорларны яисә дәүләт хезмәте стажын раслый торган документларның күчермәләре (Татарстан Республикасы дәүләт органының дәүләт граждан хезмәткәрләре реестрларының, башка вазыйфага күчерү турындагы боерыкларның, дәүләт органының атамасын үзгәртү (үзгәртеп кору) турындагы норматив хокукый актларның һ.б. күчермәләре) – дәүләт органында.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза Министрлыкта теркәлгән көннән соң 7 календарь көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: электрон формада алынган мәгълүматлар, мәгълүмат бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр.

3.4.2. Гариза гражданин тарафыннан Министрлыкка турыдан-туры тапшырылган очракта һәм Министрлыкта пенсиягә өстәмә (тиешле елларны эшләгән өчен пенсия) билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул итү өчен кирәкле белешмәләр булмаса, Министрлык белгече ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы буенча түбәндәгеләрне бирү турында электрон формада рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрә:

дәүләт вазыйфасыннан, дәүләт граждан хезмәте вазыйфасыннан җибәрү турындагы карар күчермәсе – дәүләт (муниципаль) архивында;

айлык акчалата түләү (акчалата түләү) турында белешмә – дәүләт (муниципаль) архивында;

дәүләт хезмәтенең аерым шартлары өчен вазыйфаи окладка өстәмә билгеләү турындагы боерык күчермәсе (2006 елның 1 гыйнварыннан 2018 елның 31 мартына кадәр дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләгән затлар өчен) – дәүләт (муниципаль) архивында;

дәүләт сере өчен вазыйфаи окладка өстәмә билгеләү турындагы боерык күчермәсе (2005 елның 31 декабренә кадәр дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләгән затлар өчен) – дәүләт (муниципаль) архивында;

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментының соңгы тапкыр биләгән вазыйфа буенча Татарстан Республикасы Дәүләт граждан хезмәткәрләре реестрына (алга таба – Реестр) кертү турында электрон цифрлы имза белән таныкланган расламасы (1997 елның 1 гыйнварыннан 2015 елның 31 декабренә кадәрге чорда дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләгән затлар өчен);

2016 елның 1 гыйнварыннан башлап дәүләт хезмәткәре биләгән вазыйфа буенча дәүләт хезмәткәрен Реестрга кертү турында белешмәләр – «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт кадрлар составының бердәм мәгълүмат системасы» дәүләт мәгълүмат системасында;

салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләнергә тиешле бурычлар булуы (булмавы) турында белешмәләр – Федераль салым хезмәтендә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза Министрлыкта теркәлгән көннән соң 7 календарь көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: электрон формада алынган мәгълүматлар, мәгълүмат бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр.

3.5. Пенсиягә өстәмә (тиешле елларны эшләгән өчен пенсия) билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңартып җибәрү) турында карар әзерләү.

3.5.1. Министрлык белгече алынган, 3.4.1 пунктчада күрсәтелгән белешмәләр һәм әлеге Регламентның 3.4.2 пунктчасында күрсәтелгән, ведомствоара хезмәттәшлек итү органнарыннан законнарда билгеләнгән срокларда килгән белешмәләр нигезендә, шулай ук мөрәҗәгать итүче тапшырган документлар нигезендә түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

мөрәҗәгать итүченең законлы вәкиле яисә мөрәҗәгать итүче тарафыннан вәкаләт бирелгән зат вәкаләтләрен тикшерә;

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.8 пунктында каралган нигезләр булу-булмавын тикшерә;

дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен кирәкле, әлеге Регламентның 2.8 пунктында каралган нигезләр булу-булмавын тикшерә;

әлеге Регламентның 6 нчы кушымтасындагы форма буенча пенсиягә өстәмә (тиешле елларны эшләгән өчен пенсия) билгеләү (билгеләүдән баш тарту) яки дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында карар проектын рәсмиләштерә;

пенсиягә өстәмә (тиешле елларны эшләгән өчен пенсия) билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында яки дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында карар проектын имзалау өчен министрга (министр урынбасарына) җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар алынган көннән соң 30 календарь көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процудараларның нәтиҗәсе: министрга (министр урынбасарына) имзалау өчен җибәрелгән пенсиягә өстәмә (тиешле елларны эшләгән өчен пенсия) билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында яки дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында карар проекты.

3.5.2. Министр (министр урынбасары) пенсиягә өстәмә (тиешле елларны эшләгән өчен пенсия) билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында яки дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында карар проектын карый һәм имзалый, Министрлык белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура пенсиягә өстәмә (тиешле елларны эшләгән өчен пенсия) билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында яки дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында карар проекты имзалау өчен җибәрелгән көннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процудараның нәтиҗәсе: министр (министр урынбасары) тарафыннан имзаланган пенсиягә өстәмә (тиешле елларны эшләгән өчен пенсия) билгеләү (билгеләүдән баш тарту) яки дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында карар.

3.5.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында белдерү.

Министрлык белгече пенсиягә өстәмә (тиешле елларны эшләгән өчен пенсия) билгеләү турында гаризада мөрәҗәгать итүче тарафыннан күрсәтелгән ысул белән (почта буенча язмача формада, электрон почта адресы буенча электрон документ формасында, телефонга смс-хәбәр җибәреп) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында кабул ителгән карар хакында хәбәр итә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турындагы карар имзаланган көннән соң өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында кабул ителгән карар турында хәбәр итү.

3.5.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне яңартып җибәрү яисә пенсиягә өстәмә (тиешле елларны эшләгән өчен пенсия) билгеләү турында карар кабул итү.

Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торган чорда мөрәҗәгать итүче тарафыннан әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән исемлектән җитешеп бетмәгән документлар яки мөрәҗәгать итүченең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булмавы турында белешмәләр алынса яки мөрәҗәгать итүче тарафыннан әлеге бурычны җайга салуны раслый торган документлар тапшырылса, Министрлык белгече:

әлеге Регламентка 9 нчы кушымта нигезендәге форма буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне яңартып җибәрү трында карар проектын рәсмиләштерә;

әлеге Регламентның 6 нчы кушымтасындагы форма буенча пенсиягә өстәмә (тиешле елларны эшләгән өчен пенсия) билгеләү турында карар проекты рәсмиләштерә;

дәүләт хезмәте күрсәтүне яңартып җибәрү трында карар проектын һәм пенсиягә өстәмә (тиешле елларны эшләгән өчен пенсия) билгеләү турында карар проектын имзалау өчен министрга (министр урынбасарына) җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычның булмавы яисә мөрәҗәгать итүче тарафыннан бурычларны җайга салуны раслый торган документлар тапшырылганнан соң биш эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтүне яңартып җибәрү һәм пенсиягә өстәмә (тиешле елларны эшләгән өчен пенсия) билгеләү турындагы карарларның проектлары.

3.5.5. Пенсиягә өстәмә (тиешле елларны эшләгән өчен пенсия) билгеләү турында гариза тапшырган көннән соң 90 календарь көне узганчыга кадәр мөрәҗәгать итүче тарафыннан салымнар, җыемнар һәм Россия Федерациясенең бюджет системасы бюджетларына башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан җайга салынмаган очракта, Министрлык белгече пенсиягә өстәмә (тиешле елларны эшләгән өчен пенсия) билгеләүдән баш тарту турында карар проекты әзерли һәм, имзалау өчен, министрга (министр урынбасарына) җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура пенсиягә өстәмә (тиешле елларны эшләгән өчен пенсия) билгеләү турында гариза бирелгән көннән соң 90 көн үткәч килә торган 10 календарь көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: пенсиягә өстәмә (тиешле елларны эшләгән өчен пенсия) билгеләүдән баш тарту турында карар проекты.

3.5.6. Министр (министр урынбасары) дәүләт хезмәте күрсәтүне яңартып җибәрү турында һәм пенсиягә өстәмә (тиешле елларны эшләгән өчен пенсия) билгеләү турында карарлар проектларын яисә пенсиягә өстәмә (тиешле елларны эшләгән өчен пенсия) билгеләүдән баш тарту турында кәгазь карар проектын карый, үз кулы белән имзалый һәм Министрлык белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура дәүләт хезмәте күрсәтүне яңартып җибәрү турында һәм пенсиягә өстәмә (тиешле елларны эшләгән өчен пенсия) билгеләү турындагы карарларның проектлары яки пенсиягә өстәмә (тиешле елларны эшләгән өчен пенсия) билгеләүдән баш тарту турындагы карар проекты министр (министр урынбасары) тарафыннан имзаланган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтүне яңартып җибәрү турында һәм пенсиягә өстәмә (тиешле елларны эшләгән өчен пенсия) билгеләү турында яки пенсиягә өстәмә (тиешле елларны эшләгән өчен пенсия) билгеләүдән баш тарту турында министр (министр урынбасары) тарафыннан имзаланган карарлар.

3.5.7. Министрлык белгече пенсиягә өстәмә (тиешле елларны эшләгән өчен пенсия) билгеләү турында гаризада мөрәҗәгать итүче тарафыннан күрсәтелгән ысул белән (почта буенча язмача формада, электрон почта адресы буенча элек-

трон документ формасында, телефонга смс-хәбәр җибәреп) дәүләт хезмәте күрсәтүне яңартып җибәрү турында кабул ителгән карар хакында хәбәр итә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура дәүләт хезмәте күрсәтүне яңартып җибәрү турында карарга кул куелган көннән соң өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүне яңартып җибәрү турында кабул ителгән карар турында хәбәр итү.

3.6. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

Министрлык белгече мөрәҗәгать итүчегә пенсиягә өстәмә (тиешле елларны эшләгән өчен пенсия) билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында кабул ителгән карар турында дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризада мөрәҗәгать итүче күрсәткән ысул белән (почта буенча язмача формада, электрон почта адресы буенча электрон документ формасында, телефонга смс-хәбәр җибәреп) хәбәр итә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура пенсиягә өстәмә (тиешле елларны эшләгән өчен пенсия) билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул ителгән көннән соң 10 календарь көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә пенсиягә өстәмә (тиешле елларны эшләгән өчен пенсия) билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында кабул ителгән карар турында хәбәр итү.

3.7. Техник хатаны төзәтү.

Техник хата мөрәҗәгать итүче тарафыннан, мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак бирелгән, техник хатасы булган документны (андый документ бирелгән булса) теркәп, әлеге Регламентның 10 нчы кушымтасына ярашлы форма буенча гариза бирелгән очракта төзәтелә.

3.8. Министрлык белгече:

техник хата төзәтү турындагы гаризаны кабул итә һәм гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында терки (әлеге Регламентның 11 нче кушымтасы);

Пенсиягә өстәмә (тиешле елларны эшләгән өчен пенсия) билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар проектын үзгәртеп рәсмиләштерә;

пенсиягә өстәмә (тиешле елларны эшләгән өчен пенсия) билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар проектын имзалау өчен министрга (министр урынбасарына) җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәгән вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: техник хатаны төзәтү турында кабул ителгән, теркәлгән гариза, пенсиягә өстәмә (тиешле елларны эшләгән өчен пенсия) билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән, министрга (министр урынбасарына) имзалау өчен җибәрелгән карар проекты.

3.9. Министр (министр урынбасары) пенсиягә өстәмә (тиешле елларны эшләгән өчен пенсия) билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карарны имзалый һәм аны Министрлык белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура карар проекты имзалау өчен җибәрелгән вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процудараның нәтиҗәсе: министр (министр урынбасары) тарафыннан имзаланган, пенсиягә өстәмә (тиешле елларны эшләгән өчен пенсия) билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар.

3.10. Министрлык белгече мөрәҗәгать итүчегә пенсиягә өстәмә (тиешле елларны эшләгән өчен пенсия) билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар турында гаризада мөрәҗәгать итүче тарафыннан күрсәтелгән ысул белән (почта буенча язмача формада, электрон почта адресы буенча электрон документ формасында, телефонга смс-хәбәр җибәреп) хәбәр итә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура пенсиягә өстәмә (тиешле елларны эшләгән өчен пенсия) билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар Министрлык белгеченә җибәрелгән көннән соң бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: пенсиягә өстәмә (тиешле елларны эшләгән өчен пенсия) билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар турында язмача формада почта адресы буенча яки электрон почта адресы буенча электрон документ формасында мөрәҗәгать итүчегә белдерү җибәрү.

4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору тәртибе һәм рәвешләре

4.1. Министрлык хезмәткәрләре тарафыннан әлеге Регламентның һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгели торган башка норматив хокукый актларның нигезләмәләре саклануын һәм үтәлүен даими тикшереп тору министр (министр урынбасары) тарафыннан әлеге Регламент нигезләмәләре саклануына һәм үтәлүенә тикшерүләр уздыру юлы белән гамәлгә ашырыла. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә агымдагы контрольне оештыру тәртибе һәм рәвешләре Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры тарафыннан билгеләнә.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булуын тикшерүдә тоту Министрлык Аппараты бүлегенең әлеге контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазыйфаи затлары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Административ процедуралар үтәлешен тикшереп тору рәвешләре түбәндәгеләргә карата тикшерүләр уздырудан гыйбарәт:

эшнең алып барылуына;

белешмәләрне һәм документларны карау нәтиҗәләренең законнардагы (әлеге Регламенттагы) таләпләргә туры килүенә;

документларны кабул итүнең чорлары һәм тәртибе саклануга;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә нәтиҗәләрне тапшыру чорлары һәм тәртибе саклануга.

Тикшерүләрне үткәрү ешлыгы планлы характерга (эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш характерга (мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгате буенча) ия.

4.3. Уздырылган тикшерүләр нәтиҗәсендә мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланган очракта, Министрлык хезмәткәрләре, вазыйфаи затлар дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә кабул ителә (гамәлгә ашырыла) торган карарлар һәм гамәлләр (гамәл кылмаган) өчен Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольлектә тоту дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Министрлык эшчәнлегенең ачык булуы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм төгәл мәгълүматны алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү барышында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәрге тәртиптә карап тикшерү мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең, Федераль законның 16 статьясының $1^1$ өлешендә күрсәтелгән оешмаларның, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Мөрәҗәгать итүчеләр Министрлык, Министрлыкның дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган вазыйфаи заты, дәүләт граждан хезмәткәре карар-

ларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәрге тәртиптә Министрлыкка шикаять белдерергә хокуклы.

Министр карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына шикаять белдерелергә мөмкин.

5.2. Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны теркәү чоры бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү чоры бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында дәүләт хезмәте күрсәтү өчен тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы каралмаган документларны яки мәгълүматларны тапшыру яисә гамәлләр башкару таләп ителгәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартылганда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартылганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса;

6) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) Министрлыкның, Министрлыкның вазыйфаи затының дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуы яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү срогы яисә тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм норматив хокукый актларында туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса;

10) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралган очраклардан тыш, булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүматлар таләп ителгәндә.

5.3. Министрлык, Министрлыкның дәүләт хезмәте күрсәтә торган вазыйфаи заты яисә дәүләт граждан хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять язмача кәгазьдә яки электрон формада бирелә.

Шикаять почта буенча, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк аша, «Интернет» челтәреннән файдаланып, Министрлыкның

рәсми сайтыннан (http://mtsz.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталыннан (http://uslugi.tatarstan.ru/), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.ru/) җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә дә кабул итеп алынырга мөмкин.

5.4. Шикаять алынган көненнән соңгы эш көне узганчы теркәлә. Шикаятьне карап тикшерү чоры – аны теркәүгә алганнан соңгы 15 эш көне эчендә. Министрлыкның, Министрлык вазыйфаи затының мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуын яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуын шикаять кылганда яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта, – аны теркәгәннән соңгы биш эш көне эчендә.

5.5. Шикаятьтә түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелгән дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның атамасы, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яки дәүләт граждан хезмәткәренең исеме;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), яшәгән урыны турында белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яки дәүләт граждан хезмәткәренең шикаять белдерелгән карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматлар;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның, дәүләт хезмәте күрсәтә торган органдагы вазыйфаи затның яисә дәүләт граждан хезмәткәренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезли торган дәлилләр. Мөрәҗәгать итүче үзенең дәлилләрен раслый торган документларны (булган очракта) яки аларның күчермәләрен тапшыра ала.

5.6. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган тарафыннан җибәрелгән ялгышларны һәм хаталарны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алынуы каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә дә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Әлеге пунктның 1 һәм 2 пунктчаларында күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соңгы көннән соңга калмыйча мөрәҗәгать итүчегә язмача яки, аның ихтыярына карап, электрон рәвештә шикаятьне карау нәтиҗәләре турында нигезле җавап җибәрелә.

5.7. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, җавапта мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән юк итү максатларында дәүләт хезмәте күрсәтә торган органда башкарыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсыз-

лыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәте күрсәтү максатларында алга таба мөрәҗәгать итүче эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерергә тиешле түгел дип танылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.9. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланса, шикаятьләр карауга вәкаләтле вазыйфаи зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләгән затлар пенсиясенә өстәмә һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә тиешле елларны эшләгән өчен пенсия билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

форма

Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрына

**Гомер буена айлык акчалата түләү билгеләү турында**
**ГАРИЗА**

Мин,______________________________________________________________,
(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)
яши торган адрес: ______________________________________________________
_______________________________________________________________________,
(индексын күрсәтеп, мөрәҗәгать итүченең почта адресы, телефоны, электрон почта адресы)
эш итү нигезе: ________________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтелә торган зат мәнфәгатьләрендә эш итүен раслаучы документларның реквизитлары, ышанычлы зат яисә законлы вәкил мөрәҗәгать иткән очракта)
_______________________________________________________________________,
(дәүләт хезмәте күрсәтелә торган затның фамилиясе, исеме, атасының исеме тулысынча)
яши торган адрес: ______________________________________________________
_______________________________________________________________________
(дәүләт хезмәте күрсәтелә торган затның почта адресы, яшәү урыны буенча теркәлү адресы)
_______________________________________________________________________,
(дәүләт хезмәте күрсәтелә торган затның шәхесен таныклый торган документ реквизитлары)

«Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» 2006 елның 4 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 13 статьясы нигезендә гомер буенча акчалата түләү билгеләү турында үтенәм.
Татарстан Республикасы Президенты вәкаләтләрен үтәү туктатылды _____________.
(көне, ае, елы)

«Иминият пенсияләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 400-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә пенсия ___________________________________________
(пенсия төре)
(кайда) _________________________________________________________________
(яшәү урыны буенча пенсия белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы органның атамасы)
_______________________, _______________________, _______________________.
(алып барам) (рәсмиләштердем) (алмыйм)

Тапшырылган мәгълүматларның һәм аларны үз эченә алган документларның дөреслеге өчен җаваплылык турында һәм гомер буе ай саен акчалата түләү түләүгә

йогынты ясый торган шартларның үзгәрүе турында вакытында хәбәр итү бурычы турындагы нигезләмәләр белән таныштым ________________________________.

(мөрәҗәгать итүченең имзасы)

Татарстан Республикасы Президенты вәкаләтләрен үтәүне туктаткан затка гомер буе айлык акчалата түләү билгеләгәндә федераль бюджет, Татарстан Республикасы бюджеты, Россия Федерациясенең башка субъектлары бюджетлары, җирле бюджетлар акчалары хисабыннан финанслана торган Россия Федерациясе дәүләт вазыйфасын биләгән зат пенсиясенә өстәмәгә, яки Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләгән зат пенсиясенә өстәмәгә, федераль дәүләт граждан хезмәткәренең яки муниципаль хезмәткәрнең тиешле елларны эшләгән өчен пенсиясенә, башка нигезләр буенча тиешле елларны эшләгән өчен пенсиягә, гомер буена өстәмә айлык матди керемгә, инвалидлык буенча пенсиягә (инвалидлык буенча иминият пенсиясеннән тыш), картлык буенча (инвалидлык буенча) иминият пенсиясенә ай саен башка төрле түләүгә федераль законнар, Татарстан Республикасы, Россия Федерациясенең башка субъектлары законнары, җирле үзидарә органнары актлары нигезендә хокуклы түгел икәнлегем билгеле.

Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасына яки Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына, яисә Россия Федерациясе дәүләт вазыйфасына яки федераль дәүләт хезмәте вазыйфасына, яисә Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хезмәтенә яки дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына, яисә сайлап куела торган муниципаль вазыйфага яки муниципаль хезмәт вазыйфасына кергән вакытта биш көнлек срокта бу хакта Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына хәбәр итәргә сүз бирәм.

Гомер буена айлык акчалата түләүне түбәндәгечә китерү турында үтенәм[1]:
минем счетыма күчерү юлы белән №________________________________

(законнарда билгеләнгән тәртиптә ачылган счет реквизитлары)

(кайда)________________________________;

(кредит оешмасы исеме)

почта элемтәсе бүлеге аша ________________________________;

(почта бүлеге реквизитлары)

________________________________ аша.

(пенсиягә өстәмә китерү белән шөгыльләнүче башка оешмалар)

«Персональ мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен үтәү йөзеннән, мин Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына, дәүләт вазыйфасыннан киткән дәүләт органының кадрлар хезмәтенә гомер буена айлык акчалата түләү билгеләү, түләү, яңадан исәпләү һәм түләүне туктатып тору (яңадан түли башлау) максатларында минем персональ белешмәләремне җыю, эшкәртү, шул исәптән автомат рәвештә дә, саклау, өченче затларга бирү (тапшыру) өчен ризалык бирәм.

Миңа яшәгән урынымны үзгәртү турында, Татарстан Республикасы территориясеннән яки Россия Федерациясе территориясенннән читкә даими яшәү урынына чыгып китү турында, чыгып китү датасына кадәр бер айдан алдарак булмаган чорда («Иминият пенсияләре турында»гы Федераль законның 27 статьясының 1 өлеше, «Россия Федерациясендә дәүләт пенсиясе белән тәэмин итү турында»гы Федераль

---

[1] Китерү ысулларының берсе күрсәтелә

законның 24 статьясы) Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына хәбәр итү зарурлыгы турында кисәтү ясалды.

Мәгълүмат алуга, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында да, риза:

әлеге адрес буенча язмача формада ___________________________________

әлеге телефонга смс-хәбәр итеп _____________________________________

(телефон номеры)

электрон документ формасында электрон почта адресы буенча ___________

(электрон почта адресы)

Кушымталар:

1. Шәхесне, яшьне, яшәү урынын, кайсы гражданлыкка караганлыкны таныклый торган документ күчермәсе;

2. Яшәү урыны буенча Россия Федерациясе Пенсия фондының территориаль органы тарафыннан бирелә торган, картлык буенча вакытыннан алда иминият пенсиясе билгеләү яки инвалидлык буенча иминият пенсиясе билгеләү өчен документлар белән гариза кабул итү турында дәүләт органының кадрлар хезмәте белгече тарафыннан таныкланган язу-белдерү күчермәсе, – «Иминият пенсияләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 400-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясының 1 өлеше нигезендә картлык буенча иминият пенсиясенә хокук бирә торган яшькә җиткәнче пенсия билгеләнгән очракта.

3. Хезмәт кенәгәсенең һәм (яки) Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 66, $66^1$ статьяларында билгеләнгән тәртиптә алынган, хезмәт эшчәнлеге, хезмәт стажы (2020 елның 1 гыйнварына кадәрге чорлар) турындагы белешмәләрнең күчермәсе.

4. Хәрби билет күчермәсе (хәрби хезмәт булганда).

5. Пенсиягә өстәмәләрне (пенсияләрне) китерү белән шөгыльләнә торган почта элемтәсе оешмасының яисә кредит оешмасының яки башка оешманың реквизитлары, шулай ук шәхси счет номеры.

___________________________________________________________________.

___________________________________________________________________.

___________________________________________________________________.

___________________________________________________________________.

___________________________________________________________________.

Мөрәҗәгать итүче:_____________________ _____________ «_____»_______________

(Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган затның яисә, (имза) (көне, ае, елы)
билгеләнгән тәртиптә таныкланган ышаныч
кәгазе нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтелә
торган зат мәнфәгатьләрендә эш итүче
затның ФИА)

Гариза һәм документлар кабул ителде һәм теркәлде №_____ «___» _________ ел.

(көне, ае, елы)

Дәүләт органының
мөһер урыны

_____________________________________

(Министрлыкның гаризаны теркәгән белгеченең имзасы,
фамилиясе, инициаллары һәм вазыйфасы)

Гариза һәм документлар кабул ителде һәм теркәлде №_____ «___» _________ ел.
(көне, ае, елы)

Татарстан Республикасы
Хезмәт, халыкны эш белән
тәэмин итү һәм социаль яклау
министрлыгының мөһер
урыны

_______________________________________________
(Министрлыкның гаризаны теркәгән белгеченең имзасы,
фамилиясе, инициаллары һәм вазыйфасы)

Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләгән затлар пенсиясенә өстәмә һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә тиешле елларны эшләгән өчен пенсия билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

форма

Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрына

**Пенсиягә өстәмә билгеләү турында**
**ГАРИЗА**

Мин, ______________________________________________________________,
(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)
яши торган адрес: ______________________________________________________
________________________________________________________________________,
(индексын күрсәтеп, мөрәҗәгать итүченең почта адресы, телефоны, электрон почта адресы)
эш итү нигезе: _________________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтелә торган зат мәнфәгатьләрендә эш итүен раслаучы документларның реквизитлары, ышанычлы зат яисә законлы вәкил мөрәҗәгать иткән очракта)
________________________________________________________________________,
(дәүләт хезмәте күрсәтелә торган затның фамилиясе, исеме, атасының исеме тулысынча)
яши торган адрес: ______________________________________________________
________________________________________________________________________
(дәүләт хезмәте күрсәтелә торган затның почта адресы, яшәү урыны буенча теркәлү адресы)
________________________________________________________________________,
(дәүләт хезмәте күрсәтелә торган затның шәхесен таныклый торган документ реквизитлары)

«Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» 2006 елның 4 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының $13^1$ статьясы нигезендә пенсиягә өстәмә билгеләвегез турында үтенәм.
Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе вәкаләтләрен үтәү туктатылды ____________________.
(көне, ае, елы)
«Иминият пенсияләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 400-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә пенсия ______________________________________
(пенсия төре)
(кайда) _________________________________________________________________
(яшәү урыны буенча пенсия белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы органның атамасы)
____________________, ____________________, ____________________.
(алып барам) (рәсмиләштердем) (алмыйм)

Тапшырылган мәгълүматларның, аларны үз эченә алган документларның дөрес булуы өчен җаваплылык турында һәм пенсиягә өстәмә түләүгә йогынты

ясый торган шартларның үзгәрүе турында вакытында хәбәр итү бурычы турындагы нигезләмәләр белән таныштым ________________________________

(мөрәҗәгать итүченең имзасы)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе вәкаләтләрен үтәүне туктаткан затка пенсиягә өстәмә билгеләгәндә федераль бюджет, Татарстан Республикасы бюджеты, Россия Федерациясенең башка субъектлары бюджетлары, җирле бюджетлар акчалары хисабыннан финанслана торган Россия Федерациясе дәүләт вазыйфасын биләгән зат пенсиясенә өстәмәгә, яки Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләгән зат пенсиясенә өстәмәгә, федераль дәүләт граждан хезмәткәренең яки муниципаль хезмәткәрнең тиешле елларны эшләгән өчен пенсиясенә, башка нигезләр буенча тиешле елларны эшләгән өчен пенсиягә, гомер буена өстәмә айлык матди керемгә, инвалидлык буенча пенсиягә (инвалидлык буенча иминият пенсиясеннән тыш), картлык буенча (инвалидлык буенча) иминият пенсиясенә ай саен башка төрле түләүгә федераль законнар, Татарстан Республикасы, Россия Федерациясенең башка субъектлары законнары, җирле үзидарә органнары актлары нигезендә хокуклы түгел икәнлегем билгеле.

Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасына яки Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына, яисә Россия Федерациясе дәүләт вазыйфасына яки федераль дәүләт хезмәте вазыйфасына, яисә Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хезмәтенә яки дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына, яисә сайлап куела торган муниципаль вазыйфага яки муниципаль хезмәт вазыйфасына кергән вакытта биш көнлек срокта Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына хәбәр итәргә сүз бирәм.

Пенсиягә өстәмәне түбәндәгечә җиткерү турында үтенәм[2]:

минем счетыма күчерү юлы белән №________________________________________

(законнарда билгеләнгән тәртиптә ачылган счет реквизитлары)

(кайда)____________________________________________________________;

(кредит оешмасы исеме)

почта элемтәсе бүлеге аша ____________________________________________;

(почта бүлеге реквизитлары)

____________________________________________________________________ аша.

(пенсиягә өстәмә китерү белән шөгыльләнүче башка оешмалар)

«Персональ мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен үтәү йөзеннән, мин Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына, дәүләт вазыйфасыннан киткән дәүләт органының кадрлар хезмәтенә иминият пенсиясенә өстәмә билгеләү, түләү, яңадан исәпләү һәм түләүне туктатып тору (яңадан түли башлау) максатларында минем персональ белешмәләремне җыю, эшкәртү, шул исәптән автомат рәвештә дә, саклау, өченче затларга бирү (тапшыру) өчен ризалык бирәм.

Миңа яшәгән урынымны үзгәртү турында, Татарстан Республикасы территориясеннән яки Россия Федерациясе территориясенннән читкә даими яшәү урынына чыгып китү турында, чыгып китү датасына кадәр бер айдан алдарак булмаган

---

[2] Китерү ысулларының берсе күрсәтелә

чорда («Иминият пенсияләре турында»гы Федераль законның 27 статьясының 1 өлеше, «Россия Федерациясендә дәүләт пенсиясе белән тәэмин итү турында»гы Федераль законның 24 статьясы) Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына хәбәр итү зарурлыгы турында кисәтү ясалды.

Мәгълүмат алуга, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында да, риза:
әлеге адрес буенча язмача формада_________________________________________
әлеге телефонга смс-хәбәр итеп ___________________________________________
(телефон номеры)
электрон документ формасында электрон почта адресы буенча ________________
(электрон почта адресы)

Кушымталар:

1. Шәхесне, яшьне, яшәү урынын, кайсы гражданлыкка караганлыкны таныклый торган документ күчермәсе;
2. Яшәү урыны буенча Россия Федерациясе Пенсия фондының территориаль органыннан бирелә торган, картлык буенча вакытыннан алда иминият пенсиясе билгеләү яки инвалидлык буенча иминият пенсиясе билгеләү өчен документлар белән гариза кабул итү турында дәүләт органының кадрлар хезмәте белгече тарафыннан таныкланган язу-белдерү күчермәсе, – «Иминият пенсияләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 400-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясының 1 өлеше нигезендә картлык буенча иминият пенсиясенә хокук бирә торган яшькә җиткәнче пенсия билгеләнгән очракта.
3. Хезмәт кенәгәсенең һәм (яки) Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 66, $66^1$ статьяларында билгеләнгән тәртиптә алынган, хезмәт эшчәнлеге, хезмәт стажы (2020 елның 1 гыйнварына кадәрге чорлар) турындагы белешмәләрнең күчермәсе.
4. Хәрби билет күчермәсе (хәрби хезмәт булганда).
5. Пенсиягә өстәмәләрне (пенсияләрне) китерү белән шөгыльләнә торган почта элемтәсе оешмасының яисә кредит оешмасының яки башка оешманың реквизитлары, шулай ук шәхси счет номеры.

______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________

Мөрәҗәгать итүче:___________________________ _____________ «_____»______________
(Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган затның яисә, билгеләнгән тәртиптә таныкланган ышаныч кәгазе нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтелә торган зат мәнфәгатьләрендә эш итүче затның ФИА) (имза) (көне, ае, елы)

Гариза һәм документлар кабул ителде һәм теркәлде №______ «___» __________ ел.
көне, ае, елы)

Дәүләт органының

_______________________________________________

(Министрлыкның гаризаны теркәгән белгеченең имзасы, фамилиясе, инициаллары һәм вазыйфасы)

Гариза һәм документлар кабул ителде һәм теркәлде №_____ «___» _________ ел.
(көне, ае, елы)

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының мөһер урыны

_______________________________________________

(Министрлыкның гаризаны теркәгән белгеченең имзасы, фамилиясе, инициаллары һәм вазыйфасы)

